***Фәрит Хатипов***

# ПАРЛЫ ГАШЫЙК

Җырлар

КАЗАН
ТАТАРСТАН КИТАП НӘШРИЯТЫ
2008

УДК 784
ББК 85.319
Х36

**Хатипов Ф.Х.**

Парлы гашыйк: җырлар / Фәрит Хатипов.— Казан: Татар. кит. нәшр., 2008.— 160 б.— 2000 д.—
ISBN 978-5-298-01647-6

Әлеге җыентыкка танылган композитор һәм музыкант Фәрит Хатиповның төрле елларда иҗат ителгән җырлары тупланды.

ISBN 978-5-298-01647-6
© Татарстан китап нәшрияты, 2008
© Хатипов Ф.Х., 2008

## МОҢЛЫ КӨЙЛӘР ОСТАСЫ

Салих ага Сәйдәшев, Заһид Хәбибуллин, Исмай Шәмсетдинов, Мансур Мозаффаров һәм Фасил Әхмәтовлар кебек милли музыкабызның иң халыкчан юнәлешен тоткан җыр остазларыбыздан ул Фәрит Хатипов. Татарстанның иң матур төбәкләренең берсе — Теләче районы Югары Кибәхуҗа авылында туып, укып, Арча төбәгендә үскән Фәрит гомере буе татар музыкасына хезмәт итте. Баянчы-оста буларак ул Г.Тукай исемендәге Татар дәүләт филармониясендә эшләгән чорында милли сәхнәбезнең былбыл-йолдызлары Илһам Шакиров, Хәйдәр Бигичев, Әлфия Авзалова, Габдулла Рәхимкулов, Эмиль Җәләлетдинов, Таһир Якуповларга уйный.

Без дә Фәрит Хатипов белән берничә җыр («Кил үзең», «Сиңа тиңе юк» һ.б.) иҗат иткән идек. Аларны бүген дә эстрада җырчылары бик теләп башкара.

Фәритнең Зөлфәт шигыренә язган «Һаман яратам», Хәсән Туфанның «Синең нурың», Гамил Афзалның «Гөлнарым», Фәннур Сафинның «Моңлану», Әхмәт Ерикәйнең «Җилфер-җилфер җил искәндә» шигырьләренә иҗат иткән җырларын мин югары, классик дәрәҗәдәге әсәрләре дип исәплим.

Фәрит Хатиповның җырлары халыкчан, бер-берсен кабатламый. Алар төрле характерда язылган, профессиональ югарылыкта, лирика-классика белән үрелгән романс формасындагы һәм заман ритмындагы җырлар. Композиторның бу яңа китабындагы җырларга халык үзе бәя бирер.

ӘХМӘТ ГАДЕЛ,
*шагыйрь, Татарстанның атказанган сәнгать эшлеклесе,*
*Ф.Кәрим исемендәге әдәби бүләк иясе*

## Жырым — юлдашым

*Лена Шагыйрьҗан* сүзләре

2. Бер без генәмени
Бу дөньяга үги,
Үксез моңлы җаннар меңләгән.
Җырлап алдым үчне,
Җырдан алдым көчне,
Җыр сау булса — без дә үлмәгән.
Язмыш сезнең юләр,
Уен гына, диләр,
Тик җырларда булмый алдашып.
Моңлы балаларның
Бәхете далаларда
Кала микән әллә адашып?..

3. Абынсам да түзәм,
Кагылсам да түзәм,
Сүнгәндә дә җырлап кабынсам.
Белеп түзәм икән,
Дөнья гүзәл икән,
Гомерең буе җырга табынсаң...
Яшьлек рәшә инде...
Өмет дәшә мине —
Анда нинди җырлар көтәдер?!
Яшь аралаш көләм,
Яшь аралаш җырлыйм —
Тормыш баскычлары текәдер...

4. Җыр  юлдашым белән
Җитәкләшеп киләм.
Бәхетләрнең югын бар итеп...
Мәхәббәтем килер,
Беркөн кулын бирер,
Канатына алыр пар итеп...
Җырлап кайгым басам,
Җырлап күңелем ачам,
Иртәләрем моңлы, кичләрем.
Кемнәр өчен тагын
Өзелеп җырлар идем,
Бар бит әле сез, дус-ишләрем.

## Озайт, Ходай, бераз гомеремне

*Илдар Юзеев* сүзләре

2. Узган яшьлегемне уйлый-уйлый
Иркәләнәм айның нурында.
Айга менеп җырлыйсылар килә
Җирнең матурлыгы турында.
Җирнең матурлыгы турында.

3. Шатлыгыннан күбрәк хәсрәт килде,
Бөгелсәм дә, башны имәдем.
Соңгы чиккә барып җиткәндә дә

«Туйдым синнән, дөнья...» — димәдем.
«Туйдым синнән, дөнья...» — димәдем.

4. Мин нишләрмен — вакытыннан алда
Яшәү чәчәкләрем сулсалар...
Озайт, Ходай, бераз гомеремне,
Яшиселәр киләшулкадәр!
Яшиселәр киләшулкадәр!

## Ялгыз гармун

*Резеда Вәлиева* сүзләре

2. Туган авылның тын урамнары
Оныткан инде гармун моңнарын.
Онытсын инде, уйнама юкка,
Сүнгән йөрәкне уятма, тукта.
Уйнама, гармун, җитте, кирәкми,
Әрнетмә җанны, өзмә үзәкне...

3. Өзмә үзәкне, сүнсен өметләр,
Кайтмаска киткән моннан егетләр.
Алар мәңгегә чит җирдә калган,
Газиз аналар сагынып арган...
Газиз аналар сагынып арган,
Аналар авыр йокыга талган...

Уйнама, гармун, җитте, кирәкми,
Әрнетмә җанны, өзмә үзәкне...

## Гомеркәйләр үтеп киткән

*Энҗе Мөэминова* сүзләре

2. Көзләр җиткәч, кошлар киткәч,
Таллар яфрагын коя.
Яфрак коймый, яшь коя ул,
Гомер узганын тоя.

Кушымта.

3. Яфрак койган агачларга
Җилбер-җилбер җил бәрә.
Җилбер-җилбер җил бәргәндә,
Буш оялар тирбәлә.

Кушымта.

## Агач башлары шаулыйдыр

*Харрас Әюп* сүзләре

2. Сыгыла агач башлары —
Безнең бәгырьгә тиеп.
Шуларны тыңлыйсың бугай,
Агачлар шаулый диеп.

Кушымта.

3. Киткән-озаткан чакларда
Түзәдер кемнең җаны?
И сабыр икән урманнар! —
Шаулыйлар гына бары.

Кушымта.

## Без бүген бергә әле

*Асия Юнысова* сүзләре

2. Җирдә гомер — җырлы гомер,
Кирәк түгел әллә ни.
Җиде кат күккә ашарбыз,
Йолдызларга әйләнеп.

Кушымта.

3. Сезнең янда чәчәк идек,
Үрдек гөлләр бәйләмен.
Ефәк җепләр сузып җырдан,
Йөрәкләрне бәйләдек.

Кушымта:

Без әле җирдә яшибез,
Без бүген бергә әле.
Хушлашмыйча китик әле,
Бер кайтырбыз әйләнеп.

## Ишегалларында яшел чирәм

*Хәмит Латыйф* сүзләре

2. Ишегалларында яшел чирәм,
Саргайгандыр инде, көз җиткән.
Еракларга китеп чыкмый истән,
Уйлыйм сезне, уйлыйм кич-иртән.

3. Ишегалларында яшел чирәм,
Уйларымда һаман сез икән.
Кайтып күрер идем, гомер үткән,
Чирәмнәрен көзге җил кискән.

## Көмеш яңгыры

*Георгий Ибушев* сүзләре

2. Яфрак очында җемелдәп
Тамчылар яна.
Чык яңгыры, көмеш яңгыр
Тып та тып тама.
Бөдрәләргә кагылып алсаң,
Көй чыгар сыман.
Гаҗәеп моңнар тарала
Һәрбер тамчыдан...

## Гомер юлы

*Галимҗан Гыйльманов* сүзләре

2. Яшьлегемнән килгән юлга
Кабат чыгасы иде.
Очына барып җиткәнче
Йөрәк чыдасын иде.

Кушымта.

3. Гомер юлында чәчләр дә,
Хисләр дә туза икән.
Күңелгә мәхәббәт керсә,
Гомер тиз уза икән...

Кушымта.

## Яшәү белән үлем арасында

*Ләйлә Дәүләтова* сүзләре
2. Өр-яңадан яшәп китеп була,
Сүнгәндә дә яшәү чаткысы.
Алга дәшә бик ерактан гына
Балкып торган өмет яктысы.

Кушымта.

3. Сез күмәргә ашыкмагыз мине,
Мин дөньяга тудым яңадан.
Кан-яшь түгел, җырлар чыга хәзер
Сагыш белән тулган ярадан.

Кушымта.

## Татар егете

*Шәмсия Җиһангирова* сүзләре

2. Эшкә дисәң — эшкә уңган булыр,
Телләрендә былбыл сайратыр,
Меңәрләгән кызны каратыр да
Тик берәүне генә яратыр.

Кушымта.

3. Үзенә тиң ярны сайлаганда,
Һич ялгышмас татар егете;
Үзе кебек уңган татар кызын
Сайлар гомерлеккә яр итеп.

Кушымта.

## Шаян картлар җыры

*Илдар Юзеев* сүзләре

2. Кәефләр бик күтәренке...
Базар бәясе кебек.

Бик тиз узар, яшәп калыйк,
Картлыкның кадерен белеп.

Кушымта.

3. Яшьлегемә йөгереп түгел,
Атлап та кайтмас идем.
Карчыктан да әйбәт ярны
Барыбер тапмас идем.

Кушымта.

4. Кемнәр әйтә, кем уфтана:
«Яшьлектән колак кактык...»
Картлыкның үзен яшәртеп
Яшәве — үзе шатлык.

Кушымта.

### Җыр бизәсен гомер бәйрәмен

*Фирдания Гыйльфан* сүзләре

2. Маңгайларга еллар юллар ярган,
Бушка үтмәгән шул гомерләр.
Әткәй-әнкәйләрнең хакын хаклап
Фатихалы керсез күңелләр.

Кушымта.

3. Чәчкәйләргә көмеш йөгерсә дә,
Саф мәхәббәт сердәш картлыкка.
Дуслар белән бергә кул бирешеп,
Чумып яшик бәхет-шатлыкка.

Кушымта.

### Кыр казлары

*Айрат Суфиянов* сүзләре

2. Җавап булып килде, ак томанны ярып
Күтәрелде өскә кыр казлары.
Яктылыкка чыгып җиткән кебек
Тантаналы иде авазлары.
Күтәрелде өскә кыр казлары.

Кушымта:
«Кыйгак-кыйгак, барыр җирләр ерак...»
Балкый-балкый алтын кояш бага.
...Ике иңдә корыч канат тоеп
Күтәреләм яктылыкка таба.
Кыйгак-кыйгак, барыр җирләр ерак...
Кыйгак-кыйгак, барыр җирләр ерак...

### Кайтыр әле аккошлар

*Марсель Гыймазетдинов* сүзләре

2. Бураннары, суыклары белән
Узып китәр тиздән ак кышлар.
Шаулы язлар җиткәч, гөрелдәшеп
Кайтыр әле, кайтыр аккошлар.

3. Салкыннарны алар читтә тоймас,
Ул якларда юк бит ак кышлар.
Язмышлары безнең якларда бит —
Кайтыр әле, кайтыр аккошлар.

### Каз кычкыра

*Рәфкать Хөсәенев* сүзләре

2. Китә казлар туган яктан,
Ояларын калдырып.
Китә алар кай якларга,
Канатларын талдырып.

Кушымта.

3. Казлар китәр, көзләр үтәр,
Килер яшьлегем язы.
Зәңгәр таңда, язгы күктә
Аваз салыр кыр казы.

Кушымта.

### Сандугач булыр идем

*Альбина Нигъмәтҗанова* сүзләре

2. «Моңлы бала бәхетсез»,— дип
Белми әйткән олылар.
Минем өчен җырда гына
Дөньяларның нуры бар.

Кушымта.

3. Мөмкин булса, мин үзем дә
Сандугач булыр идем.
Дәрте сүнгән күңелләргә
Дәрт булып тулыр идем.

Кушымта.

### Дуслык сүзе

*Рафис Корбан* сүзләре

2. Кичерелә калган хәтер,
Бар үпкәләр онытыла.
Сәлам биреп, исәнме, дип
Сузылганда куллар кулга.

Кушымта.

3. Кул бирешеп исәнләшсәң,
Йөрәкләргә җылы күчә.

Дуслашырга мөмкин түгел,
Исәнме, дип күрешмичә.

Кушымта.

**Авылдаш**

*Рафис Корбан* сүзләре

2. Сагындырды болын-тугайлары,
Җир җиләкле биек таулары.
Тау астына илткән басмалары,
Сандугачлы бөдрә таллары.

Кушымта.

3. Авылымның гүзәл һәр тарафы —
Сулары да аның татлырак.
Тәрәзәсе саен яран үсә,
Йолдызлар да яна яктырак.

Кушымта.

**Очрашыйк, дуслар!**

*Миңнеруй Хәбибуллина* сүзләре

2. Күрешү — бер гомер,
Югалтмыйк дуслыкны.
Тутырмас алтын да
Дусларсыз бушлыкны.

Кушымта.

3. Шушы җәй сакласын
Онытылмас мизгелләр.
Әйләнеп кайтырлар
Дуслыкка сизгерләр.

Кушымта.

**Тузганак**

*Никифор Тукмачев* сүзләре

2. Җәйге яңгыр җилләренә
Туздылар тузганаклар.
Биттән сөеп, яшем сөртеп
Уздылар тузганаклар.

Кушымта.

3. Тузганактай чәчләремне
Таратамын җилләргә.
Тузганаклар бәхетлерәк —
Тамырлары илләрдә.

Кушымта.

### Безнең урам чатыбыз

*Наил Минһаҗев* сүзләре

2. Урам чатындагы шомырт
Ак чәчәк атты микән.
Без тыңлаган пар сандугач
Яңадан кайтты микән.

Кушымта.

3. Хыялда гына булса да,
Бәлки, сиңа кайтырбыз.
Хәзер кемнәр синдә очраша,
Безнең урам чатыбыз.

Кушымта.

### Китмәгез сез, дуслар!

*Рәмис Аймәт* сүзләре

2. Яңа дуслар алар яңа инде,
Иске дуслар барыбер кадерле.
Иске дуслар, көн дә төшкә кереп,
Парә-парә телә бәгырьне.

Кушымта.

3. Безгә, дуслар, гомер юлы буйлап
Тагын күпме калды барасы?
Төзәлерме икән йөрәкләрдә
Үкенү, югалтулар ярасы?

Кушымта.

4. Соңлап аңлыйбыз шул чын дусларның
Кадерләрен исән чагында.
Дуслар иңе кирәк таянырга,
Кирәк әле безгә тагын да.

Кушымта.

### Төнге учак

*Рәмис Аймәт* сүзләре

2. Яңаралар күпме хатирәләр,
Серләшергә хәтта вакыт тар.
Безнең генә түгел, әйтерсең лә
Ялкынның да әйтер сүзе бар.

Кушымта.

3. Шунда узды безнең балачаклар,
Шунда атты яшьлек таңыбыз.
Таралсак та төрле тарафларга,
Туган якта ярты җаныбыз.

Кушымта.

4. Сагынышып искә алырбыз бер
Туган якның айлы кичләрен.
Учак сүнәр, ләкин йөрәкләрдә
Мәңге сүнмәс дуслык хисләре.

Кушымта.

### Укытучым минем

*Резеда Вәлиева* сүзләре

2. Тормышымның тәүге сукмагында
Шат елмаеп каршы алдыгыз.
Канат куеп якты хыялларга,
Олы юлга озатып калдыгыз.

Кушымта.

3. Күпме йөрәк, күпме сабый җаннар
Ялкын алган сезнең күңелдән.
Бер-бер артлы якты йолдыз булып
Кабына алар илем күгендә.

Кушымта.

### Казаным

*Эльмира Шәрифуллина* сүзләре

2. Сөембикә — асылбикә,
Сиңа килеп, хан булган.
Кол Шәрифләр иң шәрәфле
Сәетең булып торган.

3. Тукай, Такташ, Җәлилләрне
Колачыңа алгансың.
Сәйдәш, Сара, Яхиннарның
Җырын отып калгансың.

4. Мең яшьлек Казаным минем,
Мең дә берне күргәнем.
Киләчәк буыннар ачар
Тагын бик күп серләрең.

### Сабантуй килеп җитә

*Флюра Низамова* сүзләре

2. Ат уйнатып килеп керә
Ул ашлы Азнакайга,
Гармуннар уйнатып килә
Аксубайга, Чистайга.
Җилкенеп көтә бәйрәмне
Тәкәнеш тә Мамадыш,
Теләче, Минзәлә, Тәтеш,
Саба, Сарман, Актаныш.

3. Татар кайда — бәйрәм шунда,
Күп кызыклар бар анда —
Ульянда, Сергач, Бардада,
Бәләбәйдә, Шаранда.
Төркиләр иле Төмәндә,
Нугайлы Әстерханда,
Татар кыры — Ырынбурда,
Мең яшәгән Казанда.

4. Ничек көтмисең ди аны —
Бар туйларга туй бит ул,
Зур тарихлы Болгардан ук
Килгән сабантуй бит ул!
Ашкына татар йөрәге,
Бәйгеле бәйрәм көтә.
Күтәр күңел әләмеңне,
Сабантуй килеп җитә!

## Туган авылым — Мәшләгем

*Фирдания Гыйльфан* сүзләре

2. Кояш бата да, ай калка,
Яшьләр яшел болында.
Зәңгәр болын чәчәкләре
Чибәр кызлар кулында.

Кушымта.

3. Алтын башак, көмеш чишмә,
Миләш, шомырт исләре.
Тальян моңы белән ямьле
Язның айлы кичләре.

Кушымта.

## Чиләбем, Уралым

*Ирек Сабиров* сүзләре

2. Чакырды талларың,
Зөбәрҗәт урманың,
Фирүзә суларың,
Чиләбем, Уралым!

Кушымта:

Бу изге җир ямен
Моңнарда көйләдем,
Җырларда сөйләдем,
Уралым, Чиләбем!

3. Бу гүзәл дөньяның
Меңләгән юлларын
Әйләнеп-әйләнеп,
Әйләнеп урадым.

Кушымта:

Хәсрәттә терәгем,
Шатлыкта бүләгем,
Хыялым, теләгем —
Уралым, Чиләбем!

## Бикнарат наратлары

*Рафис Корбан* сүзләре

2. Бикнаратның наратлары
Болытларга орынган.
Бикнаратта тырыш халык
Яши борын-борыннан.

Кушымта.

3. Бикнаратның урамнары
Калкулык та үр генә.
Җирдә матур авыллар күп,
Ә Бикнарат бер генә.

Кушымта.

## Арча юлы

*Камил Сәгадәт* сүзләре

2. Исән-сау йөр, көтәрмен! — дип
Вәгъдә биргән,
Ак каенга чиккән яулык
Кемнәр элгән?
Җилфер-җилфер килә алар,
Оча гына.
Еракта гы җан сөйгәне
Кочагына.

3. Кыен була бу якларга
Бармагач та,
Синең яулык җилфердәр күк
Ят агачта.
Арча юлы ике яклап
Ап-ак каен.
Барам әле шул якларга,
Табам җаен.

## Ямашым

*Галимҗан Гыйльманов* сүзләре

2. Аланнарда җиләк җыйган чаклар,
Бәбкә йөрткән инеш буйлары...
Туган нигез искә төшкән саен,
Искә төшә яшьлек туйлары.

Кушымта.

3. Әнкәм килеп чыгар каршыбызга,
Яңа күлмәк бирер алмашка.
Газиз әнкәм искә төшкән саен,
Кайткан кебек булам Ямашка.

Кушымта.

## Тукай авылы җыры

*Илшат Габидуллин* сүзләре

2. Авылым уртасында күл бар,
Җәннәткә тиң бакчасы.
Шул күл белән бакчасында
Уйнап үсте барчасы.

Кушымта.

3. Безнең якта эшчән халык,
Кунакчыл, сүзгә тапкыр.
Изге ният белән килсәң,
Тукай юллары такыр.

Кушымта.

4. Мин яратам авылымны
Яшәгән халкы белән.
Йөрәгемдә туган яктан
Кабынган ялкын белән.

Кушымта.

## Ташчишмәкәй — изге чишмә

*Илдар Низамов* сүзләре

2. Суың ядрә көче белән
Җир өстенә атыла.
Аңлар өчен серләреңне
Халкым сиңа тартыла.

Кушымта.

3. Иртән кояш иркәләнсә,
Ай коена төннәрен.
Җанга рәхәт, тәнгә сихәт
Бирә суы чишмәнең.

Кушымта.

## Син кайда?

*Фәнис Яруллин* сүзләре

2. «Әтием» диясе килгән чак
Күп булды, күп булды, күп булды.
Кайчакта рәнҗүдән, үпкәдән
Күкрәктә тыннарым буылды.

Кушымта.

3. Мин инде буй җиткән кыз бала,
Күп кенә егетләр күз сала.
Әнием язмышын күрәм дә,
Сөюгә ышаныч югала.

Кушымта.

4. Әтием, синең дә мине бер
Күрәсең киләдер, ышанам.
«Кызым» дип, каршыма килсәң дә,
«Әти» дип, мин сине кочалмам.

Кушымта.

**Кимсетә күрмә кешене**

*Нурия Измайлова* сүзләре

2. Бәләкәйне «бәләкәй» ди күрмә —
Һәр җимешнең аның төше бар.
Бәләкәй генә берәүгә
Кемнеңдер зур хисе бар!

3. «Мәрхәмәтле бул балама!» — диеп,
Дога укып торган кеше бар.
Кимсетә күрмә кешене! —
Кешенең әнисе бар.
Һәркемнең әнисе бар.

**Әнкәемне бик сагынам**

*Фирая Зыятдинова* сүзләре

2. Төшкә кереп, бәгырьләрне телдең,
Күзләремә энҗе яшь элдең.
Тирән икән сагыш дәрьялары,—
Бик сагынам, әнкәй, мин сине.
Бик сагынам, әнкәй, мин сине.
Бик сагынам, әнкәй, мин сине.

3. Берни дә юк җирдә мәңгелек, дип
Юатмакчы булам үземне.
Сүзләр җитми, күздә яшьләр кипми,—
Бик сагынам, әнкәй, мин сине.
Бик сагынам, әнкәй, мин сине.
Бик сагынам, әнкәй, мин сине.

**Әнкәй**

*Фәйрүзә Мөслимова* сүзләре

2. Синнән алган йөрәк җылым
Сабыйларыма күчә.
Авылыма кайталмыйча,
Көн артыннан көн үтә.

Кушымта.

3. Мәшәкатьләр бетми һаман,
Балалар да бәләкәй...
Серләремне сиңа сөйлим
Бары төшемдә, әнкәй.

Кушымта.

**Әткәм-әнкәм минем бар әле**

*Шәмсия Җиһангирова* сүзләре

2. Ятимлекнең ни икәнен белмим,
Йөзем һәрчак көләч, ак әле,
Чөнки миңа «балам» диеп дәшәр
Әткәм-әнкәм һаман пар әле.

3. «Әти-әни» дияр кешең булу
Бәхет түгелмени, кара әле!
Мин бәхетле, шуңа рәхмәт укыйм:
Әткәм-әнкәм минем бар әле.

**Әнкәемнең туган көне**

*Резеда Вәлиева* сүзләре

2. Туган көнең синең
Зур куаныч минем
Мәхәббәтең тулы җаныма.
Өзелеп сагынып,
Кошлардай кагынып,
Ашкынып кайтамын яныңа.

3. Нурлы йөзең белән,
Назлы сүзең белән
Канатлар куйгансың җаныма.
Шул канатлар мине,
Сагынганда сине,
Алып кайта туган ягыма.
Алып кайта, әнкәй, яныңа.

**Кайтарып булмый шул әнине**

*(«Яланаяклы кыз» фильмыннан)*

*Кадрия Шакирова* сүзләре

2. Тик хыяллар болар барысы да,
Колач җитмәс чиксез хыяллар.
Әле ярый шундый хыяллар бар,
Авыр чакта тотар хыяллар.
Ул елдагы кышның салкын җиле
Әле дә бит өшетә күңелне.
Өзгәләнеп, үксеп еласак та,
Кайтарып булмый шул әнине.

**Сау бул, әни!..**

*Галия Сәетшина* сүзләре

2. Ай булып йөзеп кайтырмын,
Нурларымны сибәрмен.
Җылы кочагыңа кереп,
Битләреңнән үбәрмен.

Кушымта.

3. Язлар җитәр, кошлар кайтыр,
Сайрап, канат кагынып.
Кошлар булып мин кайтырмын,
Сине өзелеп сагынып.

Кушымта.

**Әнкәемә**

*Айрат Суфиянов* сүзләре

2. Язмышымны назлап тирбәтүче
Әнкәй кулы — җылы бишектер.
Шатлыгын да, хәсрәт-сагышын да
Һәрбер күзәнәгем ишетер.

Кушымта.

3. Кагылма син, картлык, әнкәемә,
Адымыңны берүк кичектер.
Әнкәй көлсә, әнкәй көрсенсә дә,
Ерактан да йөрәк ишетер.

Кушымта.

**Бәхетле бул, кайнана**

*Гакыйль Сәгыйров* сүзләре

2. Якын ит син, аңлый бел син аны,
Сез — аналар, алар — балалар.
Әрнетмәсен япь-яшь йөрәккәен
Нахак сүздән алган яралар.

Кушымта.

3. Ялгышма син, ана, бу дөньяда
Тормыш диеп үзе җайлана.
Бәхет телә газиз балаларга,
Бәхетле бул син дә, кайнана.

Кушымта.

**Сине юксынам, балам**

*Вахит Галиев* сүзләре

2. Урман эчләрендә алан,
Тирә-яклары балан.
Балан әчеләре баскан

Сагышларымны, балам.

Кушымта.

3. Урман эчләрендә алан,
Уртасы — сулы үзән.
Җырлыйм, елыйм сагышымнан,
Сабырлык сорыйм, түзәм.

Кушымта.

**Балачакка кайтсам...**

*Миңнеруй Хәбибуллина* сүзләре

2. Соңга калганмындыр инде,
Кадерлим дип кайтсам да,
Аз кадерләгәнмен кебек,
Өзелеп яратсам да...

Кушымта.

3. Балачакка кайтсам әгәр,
Сагынмас идем бүтән.
Шомырт чәчәген табалмыйм,
Чәчәк вакыты үткән.

Кушымта.

**Әйткән сүз — аткан ук**

*Диләә Булгакова* сүзләре

2. Уйламый әйтелгән бер сүздән
Төзәлмәс яралар ясалган.
Әйтегез: ярасыз, әрнүсез
Бармы соң арада берәр җан?

Сүзләрнең гөнаһы җуелмас,
Күңелләр хисләргә төренгән.
Бер сүздән җиде кат күкләргә
Очарлык көч безгә бирелгән.

**Бәхетемне кышларда табыйм**

*Сания Гомәрова* сүзләре

2. Тәңкә карлар ява парлашып,
Серләшәләр кебек назлашып.
Яшик, дуслар, без дә гөрләшеп,
Кар бөртекләредәй серләшеп.

3. Нурларыңда синең коенам,
Яшәү дәрте белән мин янам.
Энҗе бөртекләреңне саныйм,
Бәхетемне кышларда табыйм.

4. Ак сукмактан алга ашыгам,
Хыялымда галәмне кочам.
Ак бәхетнең ишеген кагам —
Кар бөртекләредәй мин очам.

## Тальян моңы

*Раил Сәлах* сүзләре

2. Тальянымны сузып уйнаганда,
Ямансулый ялгыз миләшем.
Минем йөрәк зарын тыңлый-тыңлый
Ул да сагышлана, күрәсең.

3. Кыңгыраулы тальян гармунымның
Аерыла алмыйм моңыннан.
Яшьлегемә кайтып киләм сыман
Тезелеп очкан кошлар юлыннан.

## Берәү гармун уйный

*Нурислам Гафиятов* сүзләре

2. Ай-йолдызлы төндә,
Төнбоеклы күлдә
Пар аккошлар суда коена.
Яшьлегемнең таңын,
Гармуннарның моңын
Сагынам мин гомер буена.

3. Ай югалган күктән,
Көн яктырган күптән,
Талга кунып сайрый сандугач.
Мин сандугач түгел,
Моңга гашыйк күңел,
Җырлыйм әле җанга моң тулгач.

## Яшьлегем, син кайларда?

*Альберт Кашаев* сүзләре

2. Үлчәп кенә Ходай биргән
Туу — яшәү арасын.
Яшьлек килә, узып китә,
Белмичә дә каласың.

Кушымта.

3. Яшьлектәге алсу таңнар
Сызылып ата көн дә.
Яшьлегемне бик сагынам,
Төшемдә түгел, өндә...

Кушымта.

## Вәгъдә биргән идем

*Әнгам Атнабаев* сүзләре

2. Әллә нишләп кайтып булмады бит,
Юллар ерак алып киттеләр...
Тупылларның яшел яфраклары
Саргаешып коелып беттеләр.

Кушымта.

3. Юк, яфраклар коелып бетмәделәр,
Бер-бер артлы еллар үттеләр.
Сагындырып еллар үттеләр дә
Күңелләрне моңсу иттеләр...

Кушымта.

**Яшьлегемә кире кайталмыйм**

*Сания Әхмәтҗанова* сүзләре

2. Йөгән кидерелгән ярсу җанны
Җибәрәсе иде тугарып.
Ат саклаган төнге болыннарга
Кайттым, ахры, бераз соңарып.

Кушымта.

3. Гармунымны алып җырлап карыйм,
Моң да башка, көй дә ят бүген.
Алмачуарымның күзләредәй,
Күңел мөлдерәп тулган чак бүген.

Кушымта.

**Бәхет чишмәсе**

*Шәмсия Җиһангирова* сүзләре

2. Ак алъяпкыч кигән нечкә генә билләр
Алган чакта сулар иелеп,
Буламыни түзеп, кызлар биле кебек
Егет күңеле китә өзелеп.

Кушымта.

3. Көянтәләр асып, вак-вак кына басып
Кайтып килә кызлар чишмәдән.
Сулар ага икән, йөрәк яна икән, —
Димәк, яшьлек әле үтмәгән.

Кушымта.

**Үткәннәр сагындыра**

*Шәмсия Җиһангирова* сүзләре

2. Гомеремнең асыл мәле —
Үткәндә чагым гына.

Шул асыл чагым уйласам,
Үткәннәр сагындыра.

3. Язмышымнан күп сорамыйм,
Сорыйм бик азын гына —
Кайтарсын иде гомернең
Шул парлы чагын гына...

**Яшьлектән кайтып киләм**

*Татар халык* сүзләре

2. Гомер юлы йомгак сыман,
Сүтеләсе сүтелгән.
Алдагысын беркем белми,
Ярты гомер үтелгән.

Кушымта.

3. Алда еллар, алда юллар,
Әле бит барыр чагым.
Зәңгәр болытларга карап,
Күпме барырмын тагын.

Кушымта.

**Моңлы көзем**

*Әмир Камалиев* сүзләре

2. Гаепләргә ашыкмагыз, зинһар,
Кенәриләр сайрый ярышып.
Тик барыбер басалмыйлар алар
Күктә очкан аккош тавышын.

Кушымта.

3. Кызганулар кирәк түгел бүген,
Үгет-нәсихәт тә кирәкми.
Салкын акыл, коры сүзләр белән
Буйсындырып булмый йөрәкне.

Кушымта.

**Бәхетем аккошлары**

*Гакыйль Сәгыйров* сүзләре

2. Мин эндәштем очкан
аккошларга:
Гомерлеккә моңлы итмәгез,
Еллар буе көткән бәхетемне
Еракларга алып китмәгез.

Сине өзелеп көтә-көтә
Үткәрдем ак кышларны.
Күрәсезме, яулык болгыйм,

Күрәсезме, яулык болгыйм,
Күрәсезме, бирeдә мин,
Бәхетем аккошлары?!

## Тәлгәш-тәлгәш миләш

*Эльмира Шәрифуллина* сүзләре

2. Бигрәк уңган миләш —
тәлгәш-тәлгәш,
Миләш уңу була суыкка.
Уйларыма һаман керәсең син,
Чыгаралмыйм хәтта куып та.

3. Баллы гына миләш —
тәлгәш-тәлгәш,
Коелып ла бетә, җыймасаң.
Үкенечтә үтә икән гомер,
Хисең белдерергә кыймасаң.

## Сез парлашып йөргән болыннар

*Рәшит Гәрәй* сүзләре

2. Болын гөлләредәй бер матурны
Сайлап ал син аннан үзеңә.
Ул елмайган чакта, якты кояш
Көлеп торсын синең йөзеңдә.

3. Яшьлек бит ул язлар кебек килә,
Матур итеп сөй һәм сөел син.
Сез парлашып йөргән болыннарда
Сезне күреп, гөлләр сөенсен.

## Нишләдең?

*Нияз Акмал* сүзләре

2. Синең өчен үртәлүдән
Йөрәкне талдырыйммы?
Мин хәзер сиңа ышанып
Дусларны калдырыйммы?
Син зәңгәр күгем идең бит,
Син зәңгәр күлем идең.
Син мондый түгел идең бит,
Гел мондый түгел идең.

3. Җәйләрнең таңы идең син,
Бураны ак кышларның.
Синең күзләр дә алдагач,
Инде кемгә ышаныйм?
Син айлы төнем идең бит,
Җыры идең чишмәнең.
Нәрсә булды сиңа, дөньям,
Нишләдең син, нишләдең?..

## Вакытлар сүтәм

*Дилә Булгакова* сүзләре

2. Җиһан сыйган олы йөрәк
Өзгәләнә бит.
Онытылган бер төнеңне
Кил дә алып кит.

...Җил капкамны кемдер ача,
Син дисәм, көзем...
Онытылган бер төнеңне
Илтимче үзем.

## Кызыл чәчәк

*Рөстәм Мингалим* сүзләре

2. Үтте кышым, сине көтеп,
Җәйләргә кердем инде...
Сиңа гына бирер өчен
Гөлләр үстердем инде...

Кушымта.

3. Су сипсәм дә, ялкын үсте,
Үсте гел кызыл чәчәк.
Синең юллар минем янга
Киләчәк ул, киләчәк.

Кушымта.

## Тау башында җиләклек

*Илдар Юзеев* сүзләре

2. Көтәм тауның
Ташында.
Бер уй гына
Башымда:
Өзелмәслек
Җиләк бул
Горур тауның
Башында.

Кушымта.

3. Һай, мин бигрәк
Түзем лә...
Өзә алмыйм
Үзем дә.
Җиләк чагың
Бер генә,
Вакыт җитми
Өзелмә...

Кушымта.

## Кыюсыз парлар

*Фәнис Яруллин* сүзләре

2. Күпме шулай йөгерербез,
Арып егылырбызмы?
Әллә олы диңгезләргә
Барып кушылырбызмы?

Кушымта.

3. Ә хәзергә чабабыз,
Шуңардан тәм табабыз.
Син бер ярда, мин бер ярда
Туктап учак ягабыз.

Кушымта.

## Җыр канатында тирбәлик

*Энҗе Мөэминова* сүзләре

2. Гөл керфекләре ачыла
Кояш нурлары белән.
Иркәлим әле җаныңны,
Җаныңны иркәлим әле
Назлы җырларым белән.

Кушымта.

3. Җыр агыла, моң агыла
Биектә, зәңгәр күктә.
Гел елмаеп тор син, иркәм,
Иркәм гел елмаеп тор син,
Күз яшьләреңне түкмә.

Кушымта.

## Әйдә барыйк аулак өйгә

*Резеда Вәлиева* сүзләре

2. Без уйный да беләбез,
Без бии дә беләбез.
Такмак әйтеп, сүз уйнатып,
Кызларны көлдерәбез.
Их, аулак өйләре,
Яңгырый дәртле көйләре.
Егетләрнең, гармун тартып,
Бер җырлап үтүләре.

3. Шаярабыз, көләбез,
Бергәләп гөр киләбез.
Аулак өйне яратабыз
Менә шуңа күрә без!
Их, аулак өйләре,
Яңгырый дәртле көйләре.
Челтер чишмә чыңнарыдай
Кызларның көлүләре!
Их, аулак өйләре,

Яңгырый дәртле көйләре.
Егетләрнең, гармун тартып,
Бер җырлап үтүләре.

**Биек тауга икәү менгән чакта**

*Әнвәр Шәрипов* сүзләре

2. Биек тауга икәү менгән чакта,
Бергә эчтек чишмә суларын.
Күңелемә мәңге кереп калды
Чишмә суларыдай моңнарың.

3. Биек тауга бүген ялгыз мендем,
Ялгыз эчтем суын чишмәнең.
Тургай җыры, чишмә суы гына
Баса алмый күңелем хисләрен...

**Яннарымда үзең булмагач**

*Ләйлә Дәүләтова* сүзләре

2. Гашыйк булу өчен мизгел җитә,
Оныттыра алмый еллар да.
Сине уйлап кына адашсам да,
Ник башкалар чыга юлларга?

Кушымта.

3. Синнән башка дөнья матурлыгын
Күрә алмыйм икән карап та.
Истәлекләр генә каршы ала
Сине эзләп чыккан тарафта.

Кушымта.

**Юксынам**

*Дамир Гарифуллин* сүзләре

2. Эзләремә тама күз яшьләре
Таң алдыннан төшкән чык сыман.
Бергә йөргән чишмә сукмакларын
Тора-тора ныграк юксынам.

Кушымта.

3. Дөньяларны, әллә хыялларны
Туган яктан читкә тарата.
Сине генә, иркәм, сине генә
Тора-тора ныграк яратам.

Кушымта.

**Минем күңел — гөлләр иле**

*Галиәхмәт Шаһи* сүзләре

2. Минем күңел — таулар иле,
Яратмасаң, ишәрсең.
Мин сагынсам, тауга менәм,
Син сагынсаң, нишләрсең?

Кушымта.

3. Минем күңел — җырлар иле,
Җырламый ничек түзим?
Күзләремдә йөрим үзем,
Җәйләрдә ике күзем.

Кушымта.

**Сине сагынам**

*Фирдания Гыйльфан* сүзләре

2. Мәңгелектән кайту мөмкин түгел икән,
Үзгәләнеп, үзелеп көтсәм дә.
Синең көчле рухың яшәү көче бирер,
Синсез ялгыз гомер итсәм дә.

Кушымта.

3. Синең иҗат юлың дәвам итәр улың,
Баяныңны саклыйм улыңа.
Күңелемнең түре бары синең өчен,
Чыгарсың күк әле дә юлыма.

Кушымта.

**Еларсың әле, еларсың...**

*Роберт Миңнуллин* сүзләре

2. Нигә инде күңелләрне
Сагышларга салырга?
Сагышымның сарылары
Сабыштыра сарыга.

Кушымта.

3. Бик сагынган чакларымда
Кемнәргә сарылырмын?
Сарылырмын, сарылырмын,
Калмады сабырлыгым.

Кушымта.

**Серем, назым...**

*Фоат Галимуллин* сүзләре

2. Җылы күлү, җылы хисләр,
Җылы елмаюларың.

Миңа алып килсен иде
Синең йөргән юлларың.

Кушымта:
Серем, назым, җылылыгым,
Оялчан мәхәббәтем.
Тоеп яшим күңелемдә
Мәхәббәтнең рәхәтен.

## Дөнья матур син булганга

*Нариман Камалов* сүзләре

2. «Сулар нигә дулкынлана?» — дисең.
Ике якта яры булганга,
Канатланган шашкын күңелкәе
Сөю хисе белән тулганга.

Кушымта.

3. «Бу мәхәббәт нигә кирәк?» — дисең.
Ансыз юктыр яшәү, күрәсең.
...Камышлар да әнә пышылдыйлар,
Кабатлыйлар сөю сүрәсен.

Кушымта.

4. Кайда дәвам, нинди киләчәк ул,
Әгәр җирдә кеше тумаса.
Җир яшәүдән туктап калыр иде,
Ярату һәм сөю булмаса.

Кушымта.

## Серенада

*Разим Вәлиуллин* сүзләре

2. Әрәмәне яңгырата,
Сайрый сандугач.
Кошлар да җырлап аңлаша,
Тигез пар булгач.
Юксынып чакыралар күк
Алар да сине.
Килче, җаным, салма инде
Сагышка мине.
Ачы ләззәт бармы икән
Сөюдән бүтән.
Күрешергә яшерен генә
Килче, кил, иркәм.

## Матурым, матуркаем

*Әхмәт Рафиков* сүзләре

2. Көйлиләрдер үз көйләрен
Янәшә ике каен.

Көй табып яшик дөньяда,
Матурым, матуркаем.

3. Өй түрендә таң алдыннан
Серләшәдер пар каен.
Гөрләшеп яшик дөньяда,
Матурым, матуркаем.

### Минеке булсаң иде

*Кадрия Шакирова* сүзләре

2. Давылларны син булганда
Курыкмый кичәр идем.
Көн дә алсу алма булып
Алдыңа төшәр идем.

3. Минеке булсаң иде син,
Бары минеке генә.
Гомергә көтәргә риза,
Ризалыгың бир генә.

4. Сагышлар да син булганда
Шатлыкка әверелә.
Минеке генә бул, иркәм,
Бары минеке генә.

### Сагынганда бер җырларсың

*Татар халык* сүзләре

2. Сине күргәч, якты кояш
Оялып ла тарсына.
Бәгырькәем, сине көтеп
Йөрәккәем ярсына.

3. Сагынганда бер җырларсың,
Җырларымны отып ал!
Гомерем буена сөярмен,
Иңнәремнән кочып ал!

4. Алсу гөлем, дияр идем,
Гөлләр мәңгелек түгел.
Син бит минем йөрәгемдә
Мәңге сүнәрлек түгел.

### Сәламеңне алдым

*Эльмира Шәрифуллина* сүзләре

2. Синең сәламеңне алдым,
Күзләрем тулы җиһан.
Каф тавы кадәрле булыр,
Шатлык хисемне җыйсам.

Кушымта.

3. Синең сәламеңне алдым,
Күңелем тулы илһам.
Җыр юллыймын,
Син дә шулай
Кабынып китәр булсаң.

Кушымта.

## Йөрәгемә яздым исемеңне

*Азат Хәнифәтуллин* сүзләре

2. Миңа сине хәтерләтә һаман
Һаваларда йөзгән ак болыт.
Яшә әле, яшә күңелемдә,
Ак болытлардан да ак булып!

Кушымта.

3. Югалтудан курыкмаган идем,
Онытудан куркам мин сине.
Ак болыттан тамган саф тамчылар
Йөрәгемә язды исемеңне.

Кушымта.

## Сизәрсең әле

*Зиннур Хөснияр* сүзләре

2. Җанымдагы ут-ялкынны
Сизмисең икән, сизмә!
Көлалганда көл инде син,
Моңая гына күрмә.

Кушымта.

3. Йөрәккәен ялкын алгач,
Үзе дә белер әле.
Сердәшенә бик яшерен
Сүз итеп сөйләр әле.

Кушымта.

4. Басмалардан чыккан чакта,
Күләгәң суга төшә.
Әнә килә көлә-көлә,
Чын сөю үзе килә.

Кушымта.

## Сиңа язам җырларымны

*Никифор Тукмачев* сүзләре

2. Хатларымны сиңа язам,
Җавап килмәс, көтсәм дә.
Үткәннәргә кайтып булмый,
Инде ни хәл итсәм дә.

Кушымта.

3. Җырларымны сиңа язам,
Җыр язылмый кирәктән.
Бу җырларым синең өчен,
Бу җыр тамды йөрәктән.

Кушымта.

## Алтын көзнең яфраклары

*Нияз Акмал* сүзләре

2. Алтын көзнең яфраклары
Ява минем юлларга.
Кайсы юллар буйлап кайтыйм
Синең елмаюларга?

Кушымта.

3. Алтын көзнең яфраклары
Әле ямь-яшел иде.
Көзге сукмаклардан эзлим
Алтындай яшьлегемне.

Кушымта.

## Төшләремдә күрәм

*Алмаз Хәмзин* сүзләре

2. Төшләремдә генә күрәм
Ап-ак, алсу төсләрне.
Таба алмам инде, ахры,
Үземә тиң ишләрне.

Кушымта.

3. Төшләремдә генә һаман
Күрәм сине, җанкаем.
Күзем ачсам, очып китә
Чиядәге кошкаем.

Кушымта.

## Көт мине, кадерлем

*Әхмәт Рафиков* сүзләре

2. Сәламнәр җибәрсәм җил белән,
Сөенеп алырсың, мин беләм.
Мин сине өзелеп сагындым,
Көт мине, көт мине, бергенәм.

3. Җибәргән хатларың күңелдә,
Рәсемең өстәлем түрендә.
Өзелеп-өзелеп сагындым,

Көт мине, көт мине, акыллым.

**Китмә**

*Шәмсия Җиһангирова* сүзләре

2. Бүтән килмәсен иде, дим,
Ә күзем — тәрәзәдә.
Җитеп сагынам башкаемны
Җуярлык дәрәҗәгә.

Кушымта.

3. Яшәвемнең бар мәгънәсе,
Сулар сулышым синдә.
Киләсең икән, китмә син,
Китәсең икән, килмә!

Кушымта.

**Көзге моң**

*Резеда Вәлиева* сүзләре

2. Чал болытлар агышы —
Аерылышу сагышы.
Һаваларда яңгырап кала
Киткән кошлар тавышы,
Киткән кошлар тавышы.

Кушымта.

3. Көзләр үтәр, язлар җитәр,
Якты нурларга тулып.
Исемең яшәр күңелемдә
Сагышлы җырлар булып,
Сагышлы җырлар булып.

Кушымта.

**Сагыну**

*Миңнеруй Хәбибуллина* сүзләре

2. Гел иснәрмен исләрен дип,
Җыйдым болын гөлләрен.
Синсез ничек үтәр инде
Моңнар тулы көннәрем.

Кушымта.

**Күзләреңдә күрәм шәүләңне**

*Вәрис Акбашев* сүзләре

2. Кочагымда калып йоклап китсәң, җаным,
Каршы алсак таңны икәүләп,
Чәчләреңнән сыйпап, керфекләрең үбеп,
Уятырмын сине иркәләп.

3. Чулпан йолдыз бүген, оныткандай күген,
Әкрен генә миңа эндәшә.
Сагыш тулган йөзе, җем-җем килә үзе,
Мине синнән, ахры, көнләшә.

4. Нинди якты дөнья, булыр идек икәү —
Каршы алсак кышлар, җәйләрне.
Бәхет өчен миңа шул да җитә, иркәм,
Күзләреңдә күрсәм шәүләңне.

### Уйлама

*Наил Төхфәтуллов* сүзләре

2. Син мине уйлама,
Яныңда булсам да,
Кышларын салкын җил
Купса да.

Кушымта.

3. Син мине уйлама,
Күңелең тулса да.
Мин дә түзәм, авыр
Булса да.

Кушымта.

### Ашкыну

*Фәнис Яруллин* сүзләре

2. Сөю алмалары учка төшәр,
Бәхет капкаларын ач кына.
Чиксезлеккә, серле чиксезлеккә
Әй ашкына йөрәк, ашкына.

Кушымта.

3. Шатлыгымны уртаклашыр өчен
Йөгерәләр гөлләр каршыма.
Язларыма, назларыма таба
Әй ашкына йөрәк, ашкына.

Кушымта.

### Өлешемә тигән көмешем

*Фәнис Яруллин* сүзләре

2. Ак каеннан алдым буй-сынны,
Чишмәләрдән җырлар өйрәндем.
Гүзәллеген салдым җырыма
Болындагы барлык гөлләрнең.

Кушымта.

3. Һәрбер кошка җылы яз кирәк,
Һәрбер җанга йомшак наз кирәк.
Тормыш җырын бергә җырларга

Чыдам кыллы моңлы саз кирәк.

Кушымта.

## Өзелеп-өзелеп яратам

*(Дуэт)*

*Шәмсия Җиһангирова* сүзләре

2. Көненә мең киңәш сорыйм
Кеп-кечкенә йөрәктән.
Гел шикләнеп кенә торам
Минем сиңа кирәктән.

3. Дөрес түгел кебек синең
Сөйләгән бер сүзең дә...
Мөлдер-мөлдер миңа юри
Карый кебек күзең дә...

4. Гел шикләнеп кенә торам,
Алып китәр дип ятлар...
Кая китте дип сагынам
Шиксез яшәгән чаклар.

5. Тагын мең төрле шигемне
Куа-куа таратам...
Тик бер нәрсәдә шигем юк —
Өзелеп-өзелеп яратам!

## Ялгыш әйттем авыр сүзләр

*Наил Минһаҗев* сүзләре

2. Сиңа әйткән авыр сүзем
Бәгыреңне телгәндер.
Йөрәгеңне кыл урталай
Телеп, кисеп бүлгәндер.

Кушымта.

3. Диңгезгә аккан суларның
Кире акмавын беләм.
Ялгыш әйткән сүзләремнең
Кире кайтмавын беләм.

Кушымта.

4. Әйтеләсе әйтелгән шул,
Булмыйдыр берни эшләп.
Якын булса да терсәкләр,
Соң инде, булмый тешләп.

Кушымта.

## Аккош күлендә томан

*Сибгат Хәким* сүзләре

2. Мин шундый томанлы төндә
Яныңа килгән идем,
Сөяргә сине гомергә
Вәгъдәләр биргән идем.

3. Көтмә, дисең, кул изисең,
Аккош күлендә томан.
Томаннарны ера-ера
Килеп чыгарсың сыман.

4. Аккош урманы ямансу,
Аккош күлендә томан.
Синең нурлы йөзләреңне
Томан аркылы күрәм.

## Агыйдел агымнары

*Роберт Миңнуллин* сүзләре

2. Агыйдел агымнары,
Әй аның агылганы...
Истә әле Агыйделдә
Аккошлар кагынганы.
Агыйдел агымнары,
Әй аның агылганы...
Истә әле Агыйделдә
Берәүнең сагынганы.

3. Агыйдел агымнары,
Әй аның агылганы...
Эзлим, эзлим шул берәүне,
Юк әле табылганы.
Агыйдел агымнары,
Әй аның агылганы...
Күңелләрнең мәхәббәттән
Юк әле арынганы.

Агыйдел агымнары...

## Уфа кайда?

*Татар халык* сүзләре

2. Уфа матур, Уфа матур,
Уфа матур ил икән.
Бу дөньяда иң читене
Айрылышкан көн икән.

3. Уфа кайда, Уфа кайда?
Уфа Урал ягында.
Кошлар булып очар идем
Бик сагынган чагында.

4. Уфа кайда, Уфа кайда?
Уфа су буйларында.

Иртән торсам, кич утырсам,
Син генә уйларымда.

**Сөеклем, бердәнберем!**

*Гамир Гайфетдин* сүзләре

2. Җан җылың күчә йөзеңә,
Көлеп әйләнәсең дә.
Мәхәббәт нурлары балкый
Кояш әйләнәсендә.

Кушымта.

3. Моңнарыңны аласыңмы
Чишмәләр агышыннан?
Җырласаң, былбыллар тына
Көнләшеп тавышыңнан.

Кушымта.

**Үзем кайтырмын, түзмәм**

*Кадрия Шакирова* сүзләре

2. Синсез яши алмавымны
Аңладым инде күптән.
Хәбәр көтәм ал таңнардан,
Йолдызлы төнге күктән.

3. Барып җитсен сәламнәрем
Таңда искән җил белән.
Очар кошлар кебек тиздән
Үзем кайтырмын, түзмәм.

**Ак яулыгым**

*Галия Сәетшина* сүзләре

2. Ак яулыгым ошамаса,
Алырмын башка төсен.
Йөрәгемнән һич чыгармыйм,
Якын бит синең исем.

Кушымта.

3. Бәйлим әле яулыгымның
Алыштырып яшелен.
Бердәнберем, мин бит сиңа
Гел сокланып яшимен.

Кушымта.

**Мәхәббәткә мәдхия**

*Шәмсия Җиһангирова* сүзләре

2. Сөюләр бер генә,
Ян әйдә син, дөрлә,
Яши бел сөюең хакына.

Хисләрең зур булса,
Сөюең чын булса,
Көч җитә түзәргә барсына.

3. Кулыбыз — кулларда,
Без бергә булганда
Сүрелмәс мәхәббәт хисләре.
Тиң парлар җирдә без,
Елыйбыз, көләбез,
Ярата беләбез бит әле.

## Мин сине эзлим әле...

*Миңнеруй Хәбибуллина* сүзләре

2. Гөлләргә тиң күңелең,
Гөлдәй матур син үзең.
Гөлләргә тиң күңелеңә
Моңнар булып түгелдем.

3. Йолдызлар күзлим әле,
Төнеңне бизим әле.
Айлы төннәремдә сине
Күкләрдән эзлим әле...

## Парлы гашыйк

*Тәслимә Низами* сүзләре

2. Җырлашып кына яшәдек,
Хәтта җырлап аңлаштык.
Чиләгенә капкачы, дип,
Бер-беребезгә ярaштык.

Кушымта.

3. Ялындырып та уйнадың —
Ялындырмадың түгел.
Сәхнә түрләрен нурлаучы
Парлы гашыйк без бүген.

Кушымта.

## Тормыш җыры

*Зиннур Хөснияр* сүзләре

2. Ялгышулар, саташулар
Сабактыр ич сиңа да.
Аерылышып ни җимердек
Бу өч көнлек дөньяда?

Кушымта.

3. Ачы сүзләр, кайнар яшьләр,
Ә ярату — хыялда.

Саклыйк әле мәхәббәтне
Бу өч көнлек дөньяда...

Кушымта.

## Син идеңме минем мәхәббәтем?

*Алсу Бикбаева* сүзләре

2. Син идеңме минем мәхәббәтем —
Иң беренче, тәүге хисләрем?
Син идең бит язгы иртәләрем,
Син идең бит айлы кичләрем!

Кушымта.

3. Син идеңме минем мәхәббәтем,
Язылмыйча калган хатларым?
Син идеңме татлы әрнүләрем,
Яшьлегемдәй керсез чакларым?

Кушымта.

## Синең өчен

*Марсель Гыймазетдинов* сүзләре

2. Синең өчен салмак җилләр исә,
Синең өчен яшен яшьни, дим.
Синең өчен җиргә килүләрем,
Синең өчен генә яшим мин.

Кушымта.

3. Тик белә күр минем кадеремне —
Югалтма син мине, югалтма...
...Мин булганга шулай гүзәл дөнья,
Син булганга шулай таң ата.

Кушымта.

## Синсез яшәү яшәү түгел

*Миңнеруй Хәбибуллина* сүзләре

2. Синсез яшәү яшәүмени,
Саулыгыңны белмәгәч.
Синең өчен өзелмәгәч,
Җаным ярып бирмәгәч.

Кушымта.

3. Синсез яшәү яшәүмени,
Эч серем сөйләмәгәч.
Кайнар кочакка сыенып
Сөймәгәч, сөелмәгәч.

Кушымта.

## Сагышлардан гына тормый күзләр

*Илдар Низамов* сүзләре

2. Яфрак тәңкәләре биешкәндә,
Язлар булып йөрәк яна ла.
Сагышлардан гына тормый күзләр,
Сөю хисе күздә яңара.

Кушымта.

3. Яңгырлардан гына тормый күзләр,
Табигатьнең алтын чуагы.
Чәчне бәйләп пәрәвезләр оча,
Күзләрнең дә була кыз чагы.

Кушымта.

## Оҗмах җимешем

*Лилия Гарипова* сүзләре

2. Син генә тик яндырасың
Бу шашкан йөрәгемне.
Бары сөю җилкендерә
Керсез, саф хисләремне.

Кушымта.

3. Өмет өзми, сине көтеп
Инде күзләрем тала.
Уртак тормыш тели-тели,
Яшьлегем үтеп бара.

Кушымта.

## Таң йолдызы

*Нурислам Гарипов* сүзләре

2. Үз йолдызым эзлим,
Өметемне өзмим,
Йөгереп менәм чишмә тавына.
Әйдә, иркәм, бераз,
Вакыт калды бик аз,
Серләшик бер чишмә шавында.

3. Таң йолдызы әнә
Нурлы балкып яна,
Кулым сузам үрелеп алырга.
Мин яратам сине,
Гашыйк итеп мине,
Ирек куйма ялгыз калырга.

## Әйтче миңа бер сүз

*Нурислам Гарипов* сүзләре

2. Ап-ак чәчкә төсле
Җанда сөю төсе,
Назларга төренгән чагым бит.

Гомеремнең нурлы,
Алтын белән тулы
Чәчәк төсле гүзәл чагы бит.

3. Ак томан эченә
Йөгер бар көчеңә,
Мин дә сиңа каршы йөгерәм.
Чәчкәләр хуш исле...
Бүләк итәр өчен,
Мин чәчкәләр өзеп өлгерәм.

## Җырларымда саклыйм

*Вахит Галиев* сүзләре

2. Еллар булды бик тә давыллы,
Ташлап киттем туган авылны.
Бөреләнгән гөлләрем калды,
Алыштырды көзләр язымны.

3. Язмышымны юрап ялгышка,
Үткән гомеремне аклыймын.
Яшьлегемә биргән назыңны
Җырларымда һаман саклыймын.

## Күзләреңдә — күзләрем

*Никифор Тукмачев* сүзләре

2. Зәңгәр күлдәй күзләрең,
Чиядәй иреннәрең.
Иреннәреңнән үбәргә
Кыймадым, үрелмәдем.

Кушымта.

3. Талдай зифа буйларың,
Сандугачтай телләрең.
Мин бит сине бер күрүдә
Бәхетемә тиңләдем.

Кушымта.

## Җитми калды бер гомер

*Никифор Тукмачев* сүзләре

2. Парлылар бәхетле, димим,
Бәхетленең тиңе бар.
Хыялның гына чиге юк,
Гомерләрнең чиге бар.

Кушымта.

3. Гомернең ачы көзләре —
Йөрәкләргә җил-давыл.
Янында парың булып та,
Ялгыз булулар авыр.

Кушымта.

## Юлларымда каеннар

*Никифор Тукмачев* сүзләре

2. Ал таңнарда тальян гармун
Уйнады кемнәр генә.
Аерылабыз, калды, җаныем,
Санаулы көннәр генә.
Санаулы көн, санаулы көн,
Килми санасыларым.
Алда икән сине сагынып
Утта янасыларым.

3. Иңнәреңә салыйм әле
Талган беләкләремне.
Сайрама, былбыл, сайрама,
Өзмә үзәкләремне.
Юлымдагы каеннарга
Кара шәлен кем япкан?
Язмасын, сезгә язмасын
Китүләр туган яктан...

## Ай күрде, кояш алды

*Нияз Акмал* сүзләре

2. Ай күрде дә, кояш алды сине,
Югалттым мин сине, югалттым.
Күңелемне мин кояшка карап,
Тулган айга карап юаттым.

3. Ай күрде дә, кояш алды сине,
Мин күрми дә калдым үзеңне.
Каян эзлим сине, каян табыйм
Тулган айдай якты йөзеңне?

## Соңгы мәхәббәт

*Галиәхмәт Шаһи* сүзләре

2. Күңелләрне сискәндереп,
Яфрак төште өзелеп.
Нигә болай соңга калдык,
Очрашмадык без элек?

Кушымта.

3. Соңгы мәхәббәт чакыра
Җиде юлның чатына —
Җир читләренә китәрмен
Шушы сөю хакына.

Кушымта.

## Син гүзәл, Гүзәлем

*Галиәхмәт Шаһи* сүзләре

2. Син йөргән юлларның читенә
Иң гүзәл чәчәкләр тезәмен.
Иң гүзәл чәчәктән кем гүзәл,
кем гүзәл?
Син гүзәл, Гүзәлем, Гүзәлем.

3. Син — миңа, мин сиңа тартылам,
Гомерне бергәләп үтәргә.
Вәгъдәләр бирешик, син — мине,
син — мине,
Мин сине бәхетле итәргә.

## Аккошым

*Иделбикә* сүзләре

2. Безнең юллар давылларда адашмасмы?
Назлы сөю алданмасмы, алдатмасмы?
Югалтмасмы янган йөрәк җан дускаен?
Ялгыштырма, адаштырма, аккошкаем.

Кушымта.

3. Сүнмәс бу ут йөрәкләрнең учагында,
Безнең юллар аккош юлы булса гына.
Алсуланып таң атканда, ай тулганда
Ташланырбыз һәрчак бәхет кочагына.

Кушымта.

## Сине сагынуларым

*Марат Кәбиров* сүзләре

2. Сабыр канатларым сынып
Сагышка уралганда,
Сине күрер өчен генә
Йөримен урамнарда.

Кушымта.

3. Урамнарда очрамыйсың,
Син кайларда йөрисең?
Өзгәләнсен әле, диеп,
Чыкмыйсыңмы юри син?!

Кушымта.

## Хыянәтең керде арага

*Рәмис Аймәт* сүзләре

2. Кирәк түгел үткәннәргә кайту,
Моң-сагышлар өстәп ярага.

Сары көзнең салкын җиле булып
Хыянәтең керде арага.

Кушымта.

3. Аерылды юллар. Ярты төндә
Кем каршылар җәеп кочагын?
Аңлый алмыйм, нигә син һаман да
Кабызмакчы сөю учагын?!

Кушымта.

4. Ни булса да, хисләр сүнгән инде,
Элеккечә булмас җан атып.
Көлгә әйләнгән безнең сөюләрне
Җилләр генә йөри таратып...

Кушымта.

**Җавапсыз мәхәббәт**

*Рәмис Аймәт* сүзләре

2. Күпме генә өзелеп яратсам да,
Кавышулар насыйп булмады.
Көтмәгәндә кинәт әллә кая
Алып китте язмыш юллары.

Кушымта:
Ява яңгыр, ява елый-елый,
Син еракта хәзер, еракта.
Елый яңгыр...
яңгырларга кушылып
Елый сыман минем йөрәк тә.

3. *Музыка (соло)*

Кушымта:
Кайтып булмый кабат үткәннәргә,
Киттең йөрәгемне яралап.
Синең аваз килә ераклардан,
Яңгыр тавышларын аралап.

**Кил син миңа**

*Рәмис Аймәт* сүзләре

2. Кышларымда килалмасаң,
Кил син, кил язларыма.
Бергә каршылыйк язларны,
Төренеп назларыма.
Көннәремне төнгә ялгап,
Көтәм сине мин һаман.
Язлар кире кайтмаса да,
Син кайтырсың, ышанам.

3. Гөл-чәчәкләргә күмелеп,

Җәйләрем көтә сине.
Нурда коенганда дөнья,
Ялгызым итмә мине.
Кайтсаң, бәхетем җиргә түгел,
Күкләргә сыймас иде.
Баш очымда пар сандугач
Җырлап туялмас иде.

4. «Инде соңарганмын!» — димә,
Кил син, кил күзләремә.
Күзнең сагыну-сагышлары
Күчмәсен йөзләремә.
«Син!» — дип типкән йөрәгемә
Күзге моң булып сарыл.
Таңда күңлем тәрәзенә
Бер яфрак булып кагыл.

## Кем гаепле?

*Рәмис Аймәт* сүзләре

2. Эзләп йөрим таныш болыннардан
Бергә яккан учак урыннарын.
Йөрәгемдә дөрли учак булып
Син кабызган сөю, сөйгән ярым.

Кушымта.

3. Бер-бер артлы еллар үтсәләр дә,
Яшим синең барлыгыңны тоеп.
Йөрәгемнән назлы исемеңне,
Юк, беркем дә ала алмас җуеп.

Кушымта.

**ЭЧТӘЛЕК**

Моңлы көйләр остасы. *Ә.Гадел*

Җырым — юлдашым. *Л.Шагыйрьҗан* сүзләре
Озайт, Ходай, бераз гомеремне. *И.Юзеев* сүзләре
Ялгыз гармун. *Р.Вәлиева* сүзләре
Гомеркәйләр үтеп киткән. *Э.Мөэминова* сүзләре
Агач башлары шаулыйдыр.*Х.Әюп* сүзләре
Без бүген бергә әле. *А.Юнысова* сүзләре
Ишегалларында яшел чирәм. *Х.Латыйф* сүзләре
Көмеш яңгыры. *Г.Ибушев* сүзләре
Гомер юлы. *Г.Гыйльманов* сүзләре
Яшәү белән үлем арасында. *Л.Дәүләтова* сүзләре
Татар егете. *Ш.Җиһангирова* сүзләре
Шаян картлар җыры. *И.Юзеев* сүзләре
Җыр бизәсен гомер бәйрәмен. *Ф.Гыйльфан* сүзләре
Кыр казлары. *А.Суфиянов* сүзләре
Кайтыр әле аккошлар. *М.Гыймазетдинов* сүзләре
Каз кычкыра. *Р.Хөсәенев* сүзләре
Сандугач булыр идем. *А.Нигъмәтҗанова* сүзләре
Дуслык сүзе. *Р.Корбан* сүзләре
Авылдаш. *Р.Корбан* сүзләре
Очрашыйк, дуслар! *М.Хәбибуллина* сүзләре
Тузганак. *Н.Тукмачев* сүзләре
Безнең урам чатыбыз. *Н.Минһаҗев* сүзләре
Китмәгез сез, дуслар! *Р.Аймәт* сүзләре
Төнге учак. *Р.Аймәт* сүзләре
Укытучым минем. *Р.Вәлиева* сүзләре
Казаным. *Э.Шәрифуллина* сүзләре
Сабантуй килеп җитә. *Ф.Низамова* сүзләре
Туган авылым — Мәшләгем. *Ф.Гыйльфан* сүзләре
Чиләбем, Уралым. *И.Сабиров* сүзләре
Бикнарат наратлары. *Р.Корбан* сүзләре
Арча юлы. *К.Сәгадәт* сүзләре
Ямашым. *Г.Гыйльманов* сүзләре
Тукай авылы җыры. *И.Габидуллин* сүзләре
Ташчишмәкәй — изге чишмә. *И.Низамов* сүзләре
Син кайда? *Ф.Яруллин* сүзләре
Кимсетә күрмә кешене. *Н.Измайлова* сүзләре
Әнкәемне бик сагынам. *Ф.Зыятдинова* сүзләре
Әнкәй. *Ф.Мөслимова* сүзләре
Әткәм-энкәм минем бар әле. *Ш.Җиһангирова* сүзләре
Әнкәемнең туган көне. *Р.Вәлиева* сүзләре
Кайтарып булмый шул әнине. *К.Шакирова* сүзләре
Сау бул, әни!.. *Г.Сәетшина* сүзләре
Әнкәемә. *А.Суфиянов* сүзләре
Бәхетле бул, кайнана. *Г.Сәгыйров* сүзләре
Сине юксынам, балам. *В.Галиев* сүзләре
Балачакка кайтсам... *М.Хабибуллина* сүзләре
Әйткән сүз — аткан ук. *Д.Булгакова* сүзләре
Бәхетемне кышларда табыйм. *С.Гомәрова* сүзләре
Тальян моңы. *Р.Сәлах* сүзләре
Берәү гармун уйный. *Н.Гафиятов* сүзләре
Яшьлегем, син кайларда? *А.Кашаев* сүзләре
Вәгъдә биргән идем. *Ә.Атнабаев* сүзләре
Яшьлегемә кире кайталмыйм. *С.Әхмәтҗанова* сүзләре
Бәхет чишмәсе. *Ш.Җиһангирова* сүзләре
Үткәннәр сагындыра. *Ш.Җиһангирова* сүзләре
Яшьлектән кайтып килә. *Татар халык* сүзләре
Моңлы көзем. *Ә.Камалиев* сүзләре
Бәхетем аккошлары. *Г.Сәгыйров* сүзләре
Тәлгәш-тәлгәш миләш. *Э.Шәрифуллина* сүзләре
Сез парлашып йөргән болыннар. *Р.Гәрәй* сүзләре
Нишләдең? *Н.Акмал* сүзләре
Вакытлар сүтәм. *Д.Булгакова* сүзләре

Кызыл чәчәк. *Р.Мингалим* сүзләре
Тау башында җиләклек. *И.Юзеев* сүзләре
Кыюсыз парлар. *Ф.Яруллин* сүзләре
Җыр канатында тирбәлик. *Э.Мөэминова* сүзләре
Әйдә барыйк аулак өйгә. *Р.Вәлиева* сүзләре
Биек тауга икәү менгән чакта. *Ә.Шәрипов* сүзләре
Яннарымда үзең булмагач. *Л.Дәүләтова* сүзләре
Юксынам. *Д.Гарифуллин* сүзләре
Минем күңел — гөлләр иле. *Г.Шаһи* сүзләре
Сине сагынам. *Ф.Гыйльфан* сүзләре
Еларсың әле, еларсың... *Р.Миңнуллин* сүзләре
Серем, назым... *Ф.Галимуллин* сүзләре
Дөнья матур син булганга. *Н.Камалов* сүзләре
Серенада. *Р.Вәлиуллин* сүзләре
Матурым, матуркаем. *Ә.Рафиков* сүзләре
Минеке булсаң иде. *К.Шакирова* сүзләре
Сагынганда бер җырларсың. *Татар халык* сүзләре
Сәламеңне алдым. *Э.Шәрифуллина* сүзләре
Йөрәгемә яздым исемеңне. *А.Хәнифәтуллин* сүзләре
Сизәрсең әле. *З.Хөснияр* сүзләре
Сиңа язам җырларымны. *Н.Тукмачев* сүзләре
Алтын көзнең яфраклары. *Н.Акмал* сүзләре
Төшләремдә күрәм. *А.Хәмзин* сүзләре
Көт мине, кадерлем. *Ә.Рафиков* сүзләре
Китмә. *Ш.Җиһангирова* сүзләре
Күзгә моң. *Р.Вәлиева* сүзләре
Сагыну. *М.Хәбибуллина* сүзләре
Күзләреңдә күрәм шәүләңне. *В.Акбашев* сүзләре
Уйлама. *Н.Төхфәтуллов* сүзләре
Ашкыну. *Ф.Яруллин* сүзләре
Өлешемә тигән көмешем. *Ф.Яруллин* сүзләре
Өзелеп-өзелеп яратам. *Ш.Җиһангирова* сүзләре
Ялгыш әйттем авыр сүзләр. *Н.Минһаҗев* сүзләре
Аккош күлендә томан. *С.Хәким* сүзләре
Агыйдел агымнары. *Р.Миңнуллин* сүзләре
Уфа кайда? *Татар халык* сүзләре
Сөеклем, бердәнберем! *Г.Гайфетдин* сүзләре
Үзем кайтырмын, түзмәм. *К.Шакирова* сүзләре
Ак яулыгым. *Г.Сәетшина* сүзләре
Мәхәббәткә мәдхия. *Ш.Җиһангирова* сүзләре
Мин сине эзлим әле... *М.Хәбибуллина* сүзләре
Парлы гашыйк. *Т.Низами* сүзләре
Тормыш җыры. *З.Хөснияр* сүзләре
Син идеңме минем мәхәббәтем? *А.Бикбаева* сүзләре
Синең өчен. *М.Гыймазетдинов* сүзләре
Синсез яшәү яшәү түгел. *М.Хәбибуллина* сүзләре
Сагышлардан гына тормый күзләр. *И.Низамов* сүзләре
Оҗмах җимешем. *Л.Гарипова* сүзләре
Таң йолдызы. *Н.Гарипов* сүзләре
Әйтче миңа бер сүз. *Н.Гарипов* сүзләре
Җырларымда саклыйм. *В.Галиев* сүзләре
Күзләреңдә — күзләрем. *Н.Тукмачев* сүзләре
Җитми калды бер гомер. *Н.Тукмачев* сүзләре
Юлларымда каеннар. *Н.Тукмачев* сүзләре
Ай күрде, кояш алды. *Н.Акмал* сүзләре
Соңгы мәхәббәт. *Г.Шаһи* сүзләре
Син гүзәл, Гүзәлем. *Г.Шаһи* сүзләре
Аккошым. *Иделбикә* сүзләре
Сине сагынуларым. *М.Кәбиров* сүзләре
Хыянәтең керде арага. *Р.Аймәт* сүзләре
Җавапсыз мәхәббәт. *Р.Аймәт* сүзләре
Кил син миңа. *Р.Аймәт* сүзләре
Кем гаепле? *Р.Аймәт* сүзләре

Нотное издание

***Хатипов*** *Фарит Ханафиевич*

ВЛЮБЛЕННЫЕ

Казань. Татарское книжное издательство. 2008

На татарском языке

Ноталы басма

***Хатипов*** *Фәрит Ханәфи улы*

ПАРЛЫ ГАШЫЙК

Музыкаль мөхәррире *И.И.Байтирәк*
Мөхәррире *В.Р.Камалиева*
Рәссамы һәм бизәлеш мөхәррире *Р.Х.Хәсәншин*
Техник мөхәррире һәм компьютерда
биткә салучысы *А.С.Газизҗанова*
Корректоры *Г.Г.Гарифуллина*

Оригинал-макеттан басарга кул куелды 22.01.2008.
Форматы 70Х00 $^1/_{16}$. Офсет кәгазе. «School Book» гарнитурасы.
Офсет басма. Шартлы басма табагы 13,0. Шартлы буяу-оттиск 13,62.
Нәшер-хисап табагы 8,52. Тиражы 2000 д. Заказ К-16.

Татарстан китап нәшрияты ДУП.
420111. Казан, Бауман урамы, 19.
**http://tatkniga.ru   e-mail: tki@tatkniga.ru**

Оригинал-макет Jahat™ программалар пакеты ярдәмендә әзерләнде.

«Идел-Пресс» полиграфия-нәшрият комплексы ААҖ.
420066. Казан, Декабристлар урамы, 2.